# ХЫЯЛ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ РАЙОНЫ
“ЧАЛМАНАРАТ ТӨП ГОМУМИ БЕЛЕМ БИРҮ МӘКТӘБЕ”НЕҢ АЙЛЫК ГАЗЕТАСЫ




## Авылым кышы

Их, авылым кышы кебек
Тагын бер кыш бар микән!
Шыгыр-шыгыр кардан
атлыйм,
Сукмаклары тар икән.
Шул тар сукмак, шул
кар-сукмак
Күңелемә бик якын.
Кар көртләре арасында,
Сукмакта синең ялкын.

### Кышкы гүзәллек

Кыш – ел фасылының иң салкыны. Алтын көз үтүгә, таягына таянып, ап-ак сакалын җирдән сөйрәп, кунакка кыш килә дә җир өстенә күбәләк-күбәләк карлар яудыра. Кар бөртекләре, җемелдәшеп, бер-берсе белән уйнап, җиргә коелалар. Шулай итеп, ул үзенең киләмен җәя.

Кыш ул битләрне өшетердәй зәмһәрир салкыннарга, күз күремен киметердәй бураннарга да бай. Көннән-көн соңрак чыккан кояш салкынча елмая. Кыш үзенең aклыгы, сафлыгы белән матур.

Чын кышны бары тик урманда гына тоярга мөмкин. Ә кырлар, яз җиткәнче, ап-ак юрганга төренеп, тыныч кына тирән йокыга талганнар. Салкын көннәрдә агачлар ап-ак бәскә төренә. Бөтен дөньяда матурлык, аклык, сихри тынлык хөкем сөрә.

Кышкы табигать искиткеч матур, ул агач буйларыннан узып киткәндә, үзеңне әкияттәгедәй хис итәсең. Андагы гүзәллекне сүзләр белән генә әйтеп бетерерлек түгел.

Сирин Имамов
8 нче класс укучысы

## Сәламәтлек турында мәкальләр

1. Байлык - бер айлык, саулык-гомерлек.
2. Саф һава - тәнгә дәва.
4. Саулыкны сатып алып булмый.
5. Арулыгым - байлыгым, тазалыгым – саулыгым.
6. Дөньяда иң кечкенә бәхет - байлык, иң зур бәхет - саулык.
7. Матурлык - сәламәтлек билгесе.
8. Сәламәт булуның бер юлы - хәрәкәт итү.
9. Гыйлемнән яхшы дус юк, чирдән яман дошман юк.
10. Саулык - зур байлык.

## Кеше сәламәтлеге нәрсәгә бәйле?

Тикшеренүләр күрсәткәнчә, сәламәтлек дәрәҗәсен 100% дип алсак, аның 20% ы – нәселдәнлек билгеләренә, 20% ы – яшәү шартларына, 10% ы – сәламәтлек саклау системасы эшчәнлегенә, ә 50% ы һәр кешенең үзенә, аның яшәү рәвешенә бәйле.




## Грипп кына димәгез!

Грипп – куркыныч авыру. Ул вирус аша йога. Вирусларны ныклап хәлсезлек тоелмаган, авыруны җиңелчә үткәреп йөргән авырулар тарата. Грипп белән авыручы әйләнә-тирәдәгеләрне сөйләшкәндә, йөткергәндә, төчкергәндә һавага төкерек, төчкерек тамчылары белән вирус таратып зарарлый. Грипп авыруын йоктырмас өчен, иң беренче чиратта, иммун системагызны ныгыту кирәк. Витаминнар күбрәк ашагыз. Шулай ук салкында юка киенеп йөрүдән, туңудан сакланыгыз. Салкын тидермәгез. Авыру янына битлек киеп керегез.

Авырып китүчегә күп итеп сыеклык эчертергә, ютәлләгәндә һәм төчкергәндә авыз-борыныгызны бер тапкыр кулланучы кулъяулыклар белән каплагыз, аннары аларны юк итегез. Онытмагыз: инфекцияне кисәтү өчен, табыныгыз бал, карлыган вареньесы, сарымсак, суган, лимон, җиләк-җимеш, тозлы кәбестә кебек ризыкларга бай булырга тиеш.

1. 10 лимон кабыгы белән вак кыргыч аша чыгарып, шуңа төелгән 10 баш сарымсак кушып бутарга.Кайнатып суытылган 3 литр җылымса су салып, суыткычка куярга.Иртән ач карынга һәм йокы алдыннан берәр кашык кабарга.
2. Күбрәк сыеклык эчегез.









## Укытучыларыбыз белән әңгәмә




**- Балачагыгызга әйләнеп кайтыр идегезме? Ни өчен?**
- Әйе, чөнки минем балачагым октябрят, пионер, комсомол чорлары белән бәйле. Ул матур вакыт иде.
- Юк. Авыр чагым булды.
- Әйе, бик теләп. Иң рәхәт, күңелле чак!
- Әйе. Бер кайгысыз, мәшәкатьсез чак булган. Проблемасыз вакыт ул.

**- Мәктәп елларыгызны сагынасызмы?**
- Сагынам. Иске мәктәптә укуымны, яңасына күчкән чакларымны сагынам. Үзебез утырткан агачларга сокланып үтәм.
- Бергәләп эшли, бәйрәмнәргә ярыша-ярыша әзерләнә, буш вакытларны файдалы итеп уздыра идек.
- Бик сагынам. Аеруча классташларымны.
- Әйе. Классташлар, укытучыларымны күрәсем килә.
- Чана, чаңгы шуулар, футбол уйнау, хәрәкәтле уеннар башкару, әдәби китаплар укуымны сагынам.

**- 10 елдан соңгы укучыларны ничегрәк күз алдына китерәсез?**
- Әллә ни үзгәрешләр булыр дип уйламыйм.
- Бик яхшы укучылар булырлар, бик тә әдәпле, заман таләпләренә туры килерлек, югалып калмый торган, проблемадан чыгу юлын таба торган итеп.
- Электрон дәреслекләрдән генә укырлар.
- Янадан укып тормаслар. Төрле яктан үсешкә ирешкән, мөстәкыйль эшләүче, белемгә омтылучы.
- Компьютерда гына утырырлар. Уку да бетәр.

**- Безнең мәктәп укучыларына нинди киңәшләр бирер идегез?**
- Тәрбияле булсыннар, олыны – олы, кечене – кече итсеннәр, әйләнә-тирәдәге кешеләргә, якыннарына игътибарлы булсыннар иде.
- Укырга, укырга, укырга!
-Укуга да, эшкә дә җаваплы карасыннар, әдәплелек кагыйдәләрен үтәсеннәр иде.
- Тырышып укырга, укытучы кушканны төгәл итеп, үзем өчен кирәк дип укырга.
- Җаваплы булырга, күбрәк укырга, белер өчен омтылырга,
- Акыллы булсыннар, кешене кеше итеп белсеннәр иде.
- Беркемне дә кыерсытмасыннар, үзләрен өстен куймасыннар, тыйнак һәм битараф булмасыннар иде.

**- Беренче дәресегезне уздырганда нинди хисләр кичердегез?**
- Дулкынлану. Укыта алырмынмы, мине аңлармы? - дип уйладым.
- Курку хисе.
- Курку, шул ук вакытта рәхәтлек тә.
- Мәктәп елларына әйләнеп кайттым.









## Укучыларыбыз белән әңгәмә




**- Укытучы булсагыз, укымаган укучыларга нәрсә әйтер идегез?**
- Укуыгыз үзегез өчен кирәк, имтихан бирәсегез бар.
- Тырышып укыгыз.
- “2”ле куям дияр идем.
- Сәбәбен сорар идем.
- Борчылма, иртәгә өйрәнеп килерсең.
- Фәннең әһәмиятен аңлатыр һәм укырга теләген күтәрер идем.
- Кисәтү ясап, дәрес әзерләүгә җаваплырак карарга кушар идем.
- Киләчәктә укучыга кирәкмәгән фәнне белер идем һәм таләп итмәс идем.
- Бүген “2”ле, иртәгә төзәтерсең.
- Ялкау булма.

**- Киләчәгеңне ничек итеп күз алдывна китерәсез?**
- 1-2 ел без эшләп, акча җыю, чит илгә барып кайту.
- Бик матур һәм бәхетле.
- Яхшы эштә эшлим.
- Бик яхшы итеп.
- Белмим.
- Бай булам.

**- 5 елдан үзеңне нинди итеп күз алдына китерәсең?**
- Армиягә китәбез.
- Укып чыгып, эшкә урнашу.
- 10 нчы класста, белемле укучы итеп.
- Мин 14 см.га үскәнмен, Актаныште укыйм.
- Казанда укыйм.
- КФУ студенты итеп.
- Үзем теләгән һөнәрне үзләштерә башлыйм.
- Бар яктан да матур кеше булам..
- Зур, көчле, белемле итеп.
- 8 нче класста булам һәм ударник булам.
- Бай кеше булам, кыйммәтле машина һәм өй алам.

**- ТДИ (ОГЭ) бетеп, имтиханны мәктәп-ләрдә бирү башланса, нинди хис кичерер идегез?**
- Җилкәдән тау төшкән кебек булыр иде.
- Бик сөенер, шатланыр идек.
- Рәхәтлек кичерер идек.
- Борчылыр идем
- Миңа барыбер.
- Иреклек хисе тояр идем.
- Җайлырак, әйбәт, шәп булыр иде.

## Сәләтле балалар өчен "Чыршы бәйрәме"

7 нче январь көнне уздырылган район башлыгы Э.Н.Фәттаховның “Чыршы бәйрәме”ндә И.Н.Локманов, Ф.Д.Гәрәев, И.В.Имамов катнашты. Аларны уңышлары белән котлыйбыз..Сәләтле укучыларыбызның саны тагын да артсын иде.

Ш.Ш.Булатов.
9 нчы класс укучысы.

«Хыял» Чалманарат төп гомуми белем бирү укучыларының фәнни-популяр, әдәби-нәфис айлык басмасы
Шеф-мөхәррир: Диана Акбулатова Җаваплы сәркатип: Миләүшә Фазлыева Фотохәбәрче: Сәйдәш Шакиров
Безнең адрес: 423752, Чалманарат авылы, Мәктәп ур., 7 нче йорт. E-mail: Schal.Akt@edu.tatar.ru, chalm.akt@yandex.ru Тираж: 15 данә Кул куелды: 14.00; 31.01.2018
Мәктәп компьютерында басылды. Бәясе ирекле. Мәкаләдәге фикерләр өчен мөхәррият җавап тотмый.